**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 636 14 июль 2015 ел

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында куркынычсызлык чаралары комплексын гамәлгә ашыру турында

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, террорчылык, экстремистик характердагы күренешләрне кисәтү, булдырмау һәм мәгариф учреждениеләренең куркынычсызлыкка даими әзерлеген тәэмин итү максатларында, «Балаларның куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү турында» 2014 елның 17 сентябрендәге 489 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2015 елның 1 сентябреннән мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Мәктәпкәчә оешмаларда террорчылыкка каршы иминлекне тәэмин итүне контрольдә тоту, үткәрү режимын көчәйтү.

1.2. Хокук саклау органнарының һәм коткару хезмәтләренең дежур хезмәтләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру (телефоннарны төгәлләштерү). Террорчылык янауларын туктату һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү буенча үзара эш итү тәртибен төгәлләргә.

1.3. Мәктәпкәчә оешмалар хезмәткәрләренә уяулыкны арттыру һәм гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта аларның гамәлләрен аңлату буенча инструктаж үткәрергә.

1.4. Учреждениеләр янында рөхсәтсез автотранспорт тукталышларына юл куймау буенча чаралар күрергә.

1.5. Балалар бакчаларында булган чорда ата-аналарның мәктәпкәчә оешмалар хезмәткәрләре белән үзара эшчәнлеге регламентын (2 биттәге кушымта)расларга.

1.6. Әлеге боерыкны 2015 елның 28 августыннан да соңга калмыйча әти әниләрГә җиткерергә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин